КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 июль г.Казань № 568

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәр-ләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел,

29 июнь, 539 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

6.3 нче пунктның 6.3.5 нче пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

6.4 нче пунктның 6.4.5 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4.5. «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесенең база һәм вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмасы исеме | База оклады, сум | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|
| «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 36 600 | 36 600»; |

Нигезләмәгә теркәлгән 4 нче кушымтага 59 нчы юлдан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «68 | «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләү | учреждениеләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләре җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор) | барлык вазыйфалар | 1 | процент | 40 | -»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең эшче гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары буенча һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «68 | «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләү | төп инженер-программист (программист), мәгълүматны саклау буенча төп белгеч, төп инженер-электроник (электроник), мәгълүматны саклау буенча төп инженер, төп аналитик | 160 |
| | | төп бухгалтер, төп икътисадчы, төп юрисконсульт | 40 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «Өченче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | бишенче квалификация дәрәҗәсе | 40 |
| | | «Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | беренче квалификация дәрәҗәсе (буйсынуында түбәндәге вазыйфалар булган бүлекләр башлыклары: төп инженер-программист (программист), мәгълүматны саклау буенча төп белгеч, төп инженер-электроник (электроник), мәгълүматны саклау буенча төп инженер, төп аналитик) | 160 |
| | | «Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | беренче квалификация дәрәҗәсе (бүлекләр башлыклары буйсынуында түбәндәге вазыйфалар булган бүлекләр башлыкларыннан тыш): төп инженер-программист (программист), мәгълүматны саклау буенча төп белгеч, төп инженер-электроник (электроник), мәгълүматны саклау буенча төп инженер, төп аналитик) | 90 |
| | | «Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | өченче квалификация дәрәҗәсе | 110». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин